БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«08» ноябрь 2021 ел

**КАРАР**
№ 344

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасының торышы мониторингы системасын һәм җылылык белән тәэмин итү системасында оператив-диспетчерлык идарәсе механизмын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җылылык чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы Россия Федерациясе Энергетика министрлыгы боерыгы нигезендә, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач муниципаль районы җылылык белән тәэмин итү системасы торышын мониторинглау системасын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Беркетеп бирелгән җылылык белән тәэмин итү системасында оператив-диспетчерлык идарәсе механизмын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Җаваплы вазыйфаи зат итеп Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесен билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның «08» 11
344 номерлы карарына
1 нче кушымта

**ТР Балтач муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасы торышын мониторинглау системасы**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Балтач муниципаль районының җылылык белән тәэмин итү системасының торышы мониторингы (алга таба - мониторинг) «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Хөкүмәтенең 2012 елның 8 августындагы 808 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә җылылык белән тәэмин итүне оештыру кагыйдәләре нигезендә башкарыла.

Җылылык белән тәэмин итү системасының торышын мониторинглау системасы - җылылык челтәрләренең, җылылык чыганакларының һәм җылылык кулланучыларның күзәтү, бәяләү һәм фаразлау комплекслы системасы.

Мониторинг - җылылык белән тәэмин итү объектларының эшчәнлеге турында даими оператив мәгълүмат алуны тәэмин итә торган процесс.

Мониторинг системасы үз эченә түбәндәгеләрне ала:

– мәгълүмат җыю системасы.
– мәгълүмат саклау, эшкәртү һәм бирү системасы.
– карар кабул итү өчен мәгълүматны анализлау һәм бирү системасы.

1.2. Мониторинг план чараларының үтәлешен анализлау һәм бәяләү максатларында гамәлгә ашырыла һәм җирле үзидарә органнарының, җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларының эш-гамәлләрен координацияләү механизмы булып тора.

1.3. Мониторингны булдыруның максаты булып җылылык белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын арттыру, җылылык белән тәэмин итү системаларын камилләштерү, үстерү, аларның тышкы мохитнең үзгәргән шартларына туры килүен тәэмин итү тора.

1.4. Мониторинг системасы муниципаль һәм объект дәрәҗәсендә гамәлгә ашырыла.

Мониторинг системасы эшчәнлеген оештыру-методик җитәкчелекне һәм координацияләүне муниципаль дәрәҗәдә Балтач район башкарма комитеты гамәлгә ашыра

Мониторинг системасы эшчәнлеген оештыру-методик җитәкчелек һәм координацияләүне объект дәрәҗәсендә җылылык белән тәэмин итүче оешма гамәлгә ашыра.

1.5. Мониторинг үткәрүнең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

– планлаштырылган чараларның фактта тормышка ашырылганнарына туры килү-килмәвен анализлау (тормышка ашыру барышын бәяләү);

– факттагы нәтиҗәләрнең аның максатларына туры килү-килмәвен анализлау (нәтиҗәлелекне анализлау);

– алынган эффект белән тормышка ашыруга юнәлдерелгән чыгымнар нисбәтен анализлау (нәтиҗәлелекне анализлау);

– тышкы шартлар үзгәрешләренең йогынтысын анализлау;

– үтәлүнең уңышлары һәм уңышсызлыклары сәбәпләрен анализлау;

– үтәлүне оештыру нәтиҗәлелеген анализлау;

– булган үзгәрешләрне исәпкә алып төзәтүләр кертә (корректировкалау), шул исәптән максатларны һәм бурычларны ачыклау.

1.6. Мониторинг үткәрүнең төп этаплары булып түбәндәгеләр тора:

– җылылык белән тәэмин итү системаларының торышы мониторингын үткәрү максатларын һәм бурычларын билгеләү;

– максатларны тормышка ашыруны, җылылык белән тәэмин итү системаларын үстерүне чагылдыручы индикаторлар системасын формалаштыру;

– гамәлгә ашыруны оператив контрольдә тоту, җылылык белән тәэмин итү системаларын үстерү һәм мәгълүмат бирү периодлылыгы өчен кирәкле планлы-хисап документлары системасын формалаштыру;

– алынган мәгълүматны анализлау.

1.7. Җылылык белән тәэмин итү системаларын үстерү мониторингы өчен кулланыла торган төп индикаторлар булып түбәндәгеләр тора:

– җылылык энергиясен эшләп чыгару күләме;

– җылылык чыганаклары куәтләренең йөкләнеше дәрәҗәсе;

– җылылык куәтләренең җылылык энергиясен кулланучыларның ихтыяҗларына туры килү дәрәҗәсе;

– карала торган чорда 1 кв. метрны җылытуга җылылык энергиясенең чагыштырма чыгымы;

– җылылык энергиясен эшләп чыгаруга ягулык чыгымының чагыштырма нормалары;

– җылылык энергиясен җитештерүгә ресурсларның чагыштырма чыгымнары;

– җылылык энергиясен транспортлауга ресурсларның чагыштырма чыгымы;

– җылылык белән тәэмин итү системаларының авария хәлендә булуы (челтәрләрнең бер километр озынлыгына берәмлек);

– кулланучыларның түләү дәрәҗәсе;

– табышлылык (рентабельлек) дәрәҗәсе.

## 2. Җылылык белән тәэмин итү системаларының торышы мониторингын үткәрү принциплары

2.1. Җылылык белән тәэмин итү системаларының торышы мониторингы эксплуатация барышының билгеләнгән планнан тайпылышларын вакытында ачыклау һәм эксплуатация барышын корректировкалау өлешендә

дә, эксплуатациянең үзен корректировкалау өлешендә дә нигезле идарә карарлары кабул итү өчен инструмент булып тора.

2.2. Җылылык белән тәэмин итү системалары мониторингы һәм аның үсешен бәяләү түбәндәге принципларга нигезләнә:

– аныклык - күрсәткечләрне төгәл билгеләү, бер хисап чорыннан икенчесенә күрсәткечләрне үлчәүнең эзлеклелеге;

– даими - мониторинг үткәрү шактый еш һәм тигез вакыт аралыгында;

– дөреслек - төгәл һәм дөрес мәгълүмат куллану, мәгълүмат җыю методларын формалаштыру.

## 3. Мәгълүмат җыю һәм системалаштыру

3.1. Мониторинг мәгълүматларын җыю системасы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җылылык челтәрләрен күзәтүнең гамәлдәге барлык методларын үз эченә ала.

3.2. Объект дәрәҗәсендә түбәндәге мәгълүмат җыела:

3.2.1. технологик җайланманың һәм җылылык челтәрләренең мәгълүматларның паспорт базасы;

3.2.2. җылылык челтәре сузуның 5 метрлы зонасында катнаш коммуникацияләр урнаштыру;

3.2.3. электрон рәвештә башкарма документлар;

3.2.4. җылылык челтәре салу зонасындагы грунт турында мәгълүматлар (грунт сулары, суффозион грунт);

3.2.5. җылылык белән тәэмин итү объектларында үткәрелгән ремонт эшләре турында мәгълүматлар;

3.2.6. җылылык белән тәэмин итү объектларын техник яктан яңадан коралландыру турында мәгълүматлар;

3.2.7. объектның исемен, объектның адресын, авария хәленә китергән сәбәпләрне, авария хәлләрен бетерү буенча күрелә торган чараларны, шулай ук кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүдән туктатып тору вакыты һәм җылылык белән тәэмин итү туктатылган кулланучылар исемлеген күрсәтеп, җылылык белән тәэмин итү объектларында килеп чыккан авария хәлләрен исәпкә алу реестры.

3.3. Муниципаль дәрәҗәдә түбәндәге мәгълүмат җыела:

3.3.1. җылылык белән тәэмин итү объектларында үткәрелгән ремонт эшләре турында мәгълүматлар;

3.3.2. җылылык белән тәэмин итү объектларын техник яктан яңадан коралландыру турында мәгълүматлар;

3.3.3. объектның исемен, объектның адресын, авария хәленә китергән сәбәпләрне, авария хәлләрен бетерү буенча күрелә торган чараларны, шулай ук кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүдән туктатып тору вакыты һәм җылылык белән тәэмин итү туктатылган кулланучылар исемлеген күрсәтеп, җылылык белән тәэмин итү объектларында килеп чыккан авария хәлләрен исәпкә алу реестры;

3.4. Җылылык белән тәэмин итүче оешма әлеге мониторингның 3.2.5; 3.2.6 һәм 3.2.7 пунктлары нигезендә, хисап аеннан соң килүче айның 5 числосына кадәр ай саен Балтач район башкарма комитетына мәгълүмат бирә.

## 4. Мәгълүматны анализлау һәм тәкъдимнәр формалаштыру

4.1. Җылылык белән тәэмин итү системаларының торышы турында мәгълүматны анализлауның төп этаплары булып түбәндәгеләр тора:

– факттагы хәлнең тасвирламасы (мәгълүмат җыю мизгеленә индикаторларның факттагы зурлыгы, тышкы мохит шартларын тасвирлау);

– хәлне динамикада анализлау (мәгълүмат җыю вакытында индикаторларның факттагы зурлыкларын исәп башлану ноктасы белән чагыштыру);

– чыгымнарны һәм эффектны чагыштыру;

– уңышларны һәм уңышсызлыкларны анализлау;

– тышкы шартлар үзгәрешләренең йогынтысын анализлау;

– файдалану (эксплуатация) нәтиҗәлелеген анализлау;

– нәтиҗә;

– киңәшләр.

4.2. Мәгълүматны анализлауның төп ысуллары булып түбәндәгеләр тора:

– күләм (сан) ягыннан - формалаштырылган математик операцияләр ярдәмендә санлы мәгълүматларны эшкәртү (уртача һәм чагыштырма зурлыкларны исәпләү, корреляция анализы, регрессия анализы һ. б.);

– сыйфат ягыннан - формалаштырылган математик ысуллар (эксперт бәяләүләре ысулы) ярдәмендә бәяләргә һәм анализларга мөмкин булмаган, элек җыелган мәгълүматларны интерпретацияләү.

4.3. Муниципаль дәрәҗәдә мониторинг мәгълүматларын анализлау район башкарма комитеты белгечләре тарафыннан башкарыла, объект дәрәҗәсендә - җылылык белән тәэмин итүче оешма белгечләре тарафыннан башкарыла.

4.4. Мониторинг мәгълүматлары объектның чын халәтен ачыклау, ялган мәгълүматны төшереп калдыру максатыннан объектның актуаль паспорт характеристикаларына йөкләнә.

4.5. Анализ мәгълүматлары нигезендә, таблица-график материалларын кулланып җылылык белән тәэмин итү системаларының торышы хисабы әзерләнә һәм җылылык белән тәэмин итү системалары эшенә төзәтмәләр кертүгә (ресурсларны яңадан бүлү һ. б.) юнәлдерелгән идарә карарларын кабул итү буенча тәкъдимнәр формалаштырыла.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның «08» 11
344 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Балтач муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасында оператив-диспетчерлык идарәсе механизмы**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системаларында оператив – диспетчерлык идарәсенең әлеге механизмы (алга таба - механизм) җылылык белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның, идарә оешмаларының һәм җылылык энергиясен кулланучыларның үзара хезмәттәшлеген билгели.

1.2. Әлеге оешмаларның төп бурычы - җылылык челтәрләренең һәм җылылык куллану системаларының тотрыклы һәм өзлексез эшләвен тәэмин итү, җылылык белән тәэмин итүнең билгеләнгән режимнарын саклау, җылылык чыганакларында, җылылык челтәрләрендә һәм җылылык куллану системаларында аварияләрне кисәтү, локальләштерү һәм бетерү буенча оператив чаралар күрү.

1.3. Җылылык белән тәэмин итүче оешма, күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтен ремонтлауны һәм карап тотуны гамәлгә ашыручы, кулланучыларны эксплуатация җаваплылыгы чикләрендә җылылык белән тәэмин итүче идарә оешмалары тәүлек буе эшләүче дежур-диспетчерлык хезмәтләре (алга таба – ДДХ) һәм авария-торгызу бригадаларына ия булырга тиеш. Штат расписаниеләрендә мондый хезмәтләр каралмаган оешмаларда оператив җитәкчелек вазыйфалары тиешле боерык белән билгеләнгән затка йөкләнә.

1.4. Җылылык белән тәэмин итүнең локаль системасын эксплуатацияләү буенча ДДХ гамәлләрен гомуми координацияләүне җылылык белән тәэмин итүче оешма башкара, авария хәлен локальләштерү һәм бетерү буенча - аның эксплуатация җаваплылыгы чикләрендә авария хәле барлыкка килгән оешманың авария – торгызу хезмәте.

1.5. Аварияләрне локальләштерү һәм бетерү эшләрен башкару өчен һәр оешмада кирәкле инструментлар, механизмнар, транспорт, күчмә эретеп ябыштыру җайланмалары, терәк арматурасының һәм материалларның авария хәле өчен тулыланып торучы запаслары булырга тиеш. Авария хәле өчен запас күләме гамәлдәге нормативларга туры китереп билгеләнә, саклау урыны тиешле оешмаларның җитәкчеләре тарафыннан билгеләнә. Авария-торгызу бригадаларының составы, машиналар һәм механизмнар, җайланмалар һәм материаллар исемлеге оешманың баш инженеры тарафыннан раслана.

1.6. Җылылык белән тәэмин итүдә озак вакытлы өзеклекләр китереп чыгара торган эшләр күләме шактый булса, Балтач район башкарма комитеты

җитәкчесе карары белән торгызу эшләренә махсус төзелеш-монтаж һәм башка предприятиеләр җәлеп итеелә.

## 2. Энергия белән тәэмин итү чыганакларында, энергия куллану системаларында һәм челтәрләрдә аварияләр барлыкка килгәндә һәм аны бетергәндә оператив-диспетчерлык һәм авария-торгызу хезмәтләренең үзара хезмәттәшлеге

2.1. Авария килеп чыгу, кулланучыларны энергия белән тәэмин итүдән туктату яки чикләү турында хәбәр алганда, тиешле оешма диспетчеры авария урынында куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча оператив чаралар күрә (койма, яктырту, саклау һ.б.) һәм авария хәлләрен бетерү буенча инструкция нигезендә эшли.

2.2. Авария хәле турында диспетчер кичекмәстән үзе булган элемтә каналлары буенча оешма җитәкчелегенә, үз җайланмаларының һәм коммуникацияләренең эшен үзгәртергә яки туктатырга кирәк булган оешмалар диспетчерларына, кулланучыларның диспетчерлык хезмәтләренә хәбәр итә.

Шулай ук авария хәленең килеп чыгуы һәм кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүне яңадан торгызу вакыты турында мәҗбүри рәвештә бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенә (алга таба – БДДХ) һәм Балтач район башкарма комитетына хәбәр ителә.

2.3. Җылылык белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык челтәрләрендә авария барлыкка килгәндә җылылык белән тәэмин итүче оешма диспетчеры бу хакта кичекмәстән бу хакта бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенә һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә агымдагы ремонтлауны һәм карап тотуны гамәлгә ашыручы идарә оешманың җаваплы затына хәбәр итә.

2.4. Кулланучыларга җылылык энергиясе бирүне чикләү яки туктату режимын кертү турында карар, ТР Балтач район башкарма комитеты белән килештереп, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар җитәкчелеге тарафыннан кабул ителә

2.5. Җылылык белән тәэмин итү һәм җылылык куллану системаларын өзү һәм бушату турында командалар тиешле диспетчерлык хезмәтләре аша уза.

2.6. Авария нәтиҗәсендә кешеләр тормышына, җайланманың, инженерлык коммуникацияләренең яки төзелешләрнең җимерелүенә куркыныч яныса, җылылык белән тәэмин итүче оешма җитәкчелеге, килештермичә генә, әмма өзеп кую алдыннан һәм авария хәлендәге җылылык-механик җайланманы яисә җылылык челтәрләре участогын эштән чыгару буенча эшләрне тәмамлаганнан соң, кичекмәстән БДДХ диспетчерына, ТР Балтач район башкарма комитетына һәм кулланучыларга (кирәк очракта) хәбәр итеп, җайланманы эштән чыгаруга күрсәтмә бирә.

2.7. Аварияне бетерү өчен җаваплы зат түбәндәгеләргә бурычлы:

- кирәк булганда, диспетчерлык хезмәтләре аша авария урынында коммуникацияләре, корылмалары булган тиешле оешма һәм ведомство вәкилләрен чакыртырга, алар белән аварияне бетерү өчен җир эшләре үткәрүне килештерергә;

- җир асты коммуникацияләрендә эшләр башкаруны оештырырга һәм эшләр башкаруның имин шартларын тәэмин итәргә;

- эш схемасын, бирелгән җылылык белән тәэмин итү параметрларын торгызу һәм пуск программасы нигезендә кулланучыларны тоташтыру өчен тиешле диспетчерлык хезмәтләренә авария-торгызу эшләре (яки нинди дә булса этап) тәмамлану турында хәбәр итәргә.

2.8. Авария килеп чыккан урында үз коммуникацияләре яки корылмалары булган барлык милек формасындагы оешмалар һәм предприятиеләр үз вәкилләрен тәүлекнең теләсә кайсы вакытында 2 сәгать эчендә аварияне бетерү буенча эшләрне башкару шартларын килештерүгә җибәрергә тиеш.

## 3. Энергия белән тәэмин итү системаларын эксплуатацияләгәндә оператив-диспетчерлык хезмәтләренең үзара хезмәттәшлеге

3.1. Кулланучыларны планлы рәвештә җылылык бирүдән өзүне (җылылык чыганагының параметрларын үзгәртүне) раслау өчен җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның диспетчерлык хезмәтләре билгеләнгән эшләргә 5 көн кала ТР Балтач район башкарма комитетына һәм кулланучыларга хәбәр итә.

3.3. Кулланучылар (юридик затлар) балансында булган җайланманы ремонтлауга чыгаруга планлаштыру билгеләнгән эшләргә 5 көн кала, ә авария булган очракта - кичекмәстән Балтач район башкарма комитетына мәҗбүри хәбәр итеп башкарыла.

3.4. Җылылык чыганакларына салкын су бирүне чикләүгә яки туктатуга китерә торган су алу корылмаларында планлы ремонт эшләре башкарганда, әлеге су алу корылмалары алар карамагында булган оешма диспетчеры җылылык белән тәэмин итүче тиешле оешма диспетчерына, БДДХнә, ТР Балтач район башкарма комитетына 10 көн эчендә эшләрнең башлану һәм тәмамлау вакытларын күрсәтеп, әлеге туктатулар турында хәбәр итәргә тиеш.

Котельныйларга салкын су бирүне озак вакытка туктатуга китергән аварияләрдә җылылык белән тәэмин итүче оешма диспетчеры, аны тулысынча туктатуга кадәр җитеп, кулланучыларны кайнар су белән тәэмин итүне чикли.

3.5. Алар җылылык белән тәэмин итү системасы объектларына электр энергиясен бирүне чикләүгә яки туктатуга китерә торган, электр челтәрләрендә һәм трансформатор подстанцияләрендә планлы яки авария-торгызу эшләрен башкарганда, әлеге электр челтәрләре һәм трансформатор подстанцияләре алар карамагында булган оешма диспетчеры 10 көн эчендә яки кичекмәстән тиешле җылылык белән тәэмин итүче оешма диспетчерына, БДДХ диспетчерына һәм Балтач район башкарма комитетына эшләрне башлау һәм тәмамлау вакытын күрсәтеп, бу туктатулар турында хәбәр итәргә тиеш.

3.6. Тышкы һава температурасы җылылык белән тәэмин итү системасының җылылык чыганакларында җылылык генерациясе куәтләре җитми торган күрсәткечләргә кадәр кимегән очракта, җылылык белән тәэмин итүче оешма диспетчеры, ТР Балтач районы башкарма комитеты белән килештереп, кулланучыларга җылылык энергиясен җибәрүне чикли.

3.7. Яңа объектларны тоташтыру бары тик Экология, технология һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәт (Ростехнадзор) һәм җылылык белән тәэмин

итүче оешма рөхсәте буенча гына бер үк вакытта Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына хәбәр итеп башкарыла.

3.8. Кулланучының язма гаризасы буенча ремонтка чыгарылган объектларны тоташтыру җылылык белән тәэмин итүче оешмалар персоналы рөхсәте буенча гаризада күрсәтелгән кулланучының җаваплы заты үтенече буенча башкарыла. Гаризалар буенча эшләр төгәлләнгәннән соң югарыда аталган предприятиеләрнең һәм оешмаларның оператив җитәкчеләре ТР Балтач район башкарма комитетына тоташтыруны башлау вакытын хәбәр итәләр.

## 4. Техник документлар

Җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның оператив-диспетчерлык хезмәтләренең һәм җылылык энергиясен кулланучыларның үзара мөнәсәбәтләрен билгели торган документлар булып түбәндәгеләр тора:

- әлеге Механизм;
- куркынычсызлык техникасы һәм җылылык генерацияләү җайланмаларын, җылылык челтәрләрен һәм җылылык кулланучы җайланмаларны эксплуатацияләү буенча гамәлдәге норматив-техник документлар;
- гамәлдәге норматив-техник документларны исәпкә алып эшләнгән әлеге җайланманы эксплуатацияләүгә һәм аның куркынычсызлык техникасына кагылышлы эчке инструкцияләр;
-җылылык белән тәэмин итүче оешма җитәкчесе тарафыннан расланган җылылык энергиясе җайланмаларында авария һәм гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча авария-ремонт бригадаларының эш-гамәлләре планы.

Эчке инструкцияләр аварияләрдә, җылылык энергиясе, электр егәрлеге яки җылылык белән тәэмин итү чыганакларында ягулык җитмәү вакытында кулланучыларны тәэмин итүне чикләгәндә һәм өзеп торганда җентекләп эшләнгән оператив гамәлләр планын үз эченә алырга тиеш.

Инструкцияләргә мөмкин булган авария хәлендәге күчерүләрнең схемалары беркетелергә, кайнар су белән тәэмин итүне һәм җылылык бирүне туктатып тору, җылылык челтәрләрен һәм биналарның җылылык белән тәэмин итү системаларын бушату, алга таба аларны тутыру һәм авария режимнарының эшләнгән вариантларында эшкә кертү тәртибе күрсәтелгән булырга тиеш, җылылык белән тәэмин итүнең көчәйтелгән һәм хисаптан тыш режимнарында персоналның дежур торуларын һәм гамәлләрен оештыру билгеләнергә тиеш.

Һәр оешмада кирәкле эксплуатация документларының конкрет исемлеге аның җитәкчелеге тарафыннан билгеләнә.